ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 21 мартындагы 152 номерлы карары белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планының VII бүлегендәге кырык алтынчы абзацы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 20 февралендәге 675 номерлы карары белән расланган 2016—2017 елларда Казан шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планының V бүлеге, шулай ук тулысынча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының аталган карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Җ. Галимҗанова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында**

Казан шәһәре 2017 елның 10 мае

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында гражданка Г.Җ. Галимҗанова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында судья А.Р. Шакараев мәгълүматын тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Җ. Галимҗанова «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 21 мартындагы 152 номерлы карары белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планының VII бүлегендәге кырык алтынчы абзацы белән, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 20 февралендәге 675 номерлы карары белән расланган 2016—2017 елларда Казан шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планының V бүлеге белән, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының аталган карары белән тулысынча аны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Ләкин 2017 елның 20 мартында гражданка Г.Җ. Галимҗанова Татарстан Республикасы Конституция судына үзенең шикаятен кире алуы турында гариза белән мөрәҗәгать итте.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы ук мөрәҗәгать

итүче тарафыннан кире алынырга мөмкин. Мөрәҗәгать кире алынган очракта эшне карау туктатыла.

Мөрәҗәгать итүче үз шикаятен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эш карала башланганчыга кадәр кире алганга күрә, әлеге шикаять буенча эш башкару туктатылырга тиеш.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 72 статьясына һәм 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 21 мартындагы 152 номерлы карары белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планының VII бүлегендәге кырык алтынчы абзацы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 20 февралендәге 675 номерлы карары белән расланган 2016—2017 елларда Казан шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планының V бүлеге, шулай ук тулысынча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма

комитетының аталган карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Җ. Галимҗанова шикаяте буенча эш башкаруны, мөрәҗәгать итүченең әлеге шикаятьне кире алуы сәбәпле, туктатырга.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Җ. Галимҗановага җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 11-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**